КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 8 август г.Казань № 648

Мәгариф өлкәсендә грантлар турында

Белем бирүнең сыйфатын күтәрү, гомуми белем бирү оешмаларының һәм һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә, гомуми белем бирү оешмаларының яшь белгечләренә, директорларына, методистларга, тәрбия һәм укыту-методик эш буенча директор урынбасарлары, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, интернаты булган гомуми белем бирү оешмаларына, шул исәптән сәләтле балалар өчен дә, ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Мәгариф өлкәсендә түбәндәге грантларны гамәлгә куярга:
«Безнең яңа укытучы»;
«Иң яхшы билингваль балалар бакчасы»;
«Белем бирү сыйфатын бәяләү өлкәсендә иң яхшы эксперт»;
«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә ярдәм итү»;
«Оста мөгаллим»;
«Татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадаларында һәм татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадада җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән өчен татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм итү»;
«Иң яхшы оста»;
«Иң яхшы укытучы»;
«Һөнәри белем бирү оешмасының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе»;
«Иң яхшы мәктәп директоры»;
«Безнең иң яхшы методист»;
«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмасының иң яхшы педагогы»;
«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр»;
«Уңышлы мәктәп»;
«Мәктәп укучыларының бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы

җиңүчеләрен һәм призерларын әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм итү».

2. Карарга теркәлгәннәрне расларга:

«Безнең яңа укытучы» гранты турында нигезләмә;

«Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турында нигезләмә;

«Белем бирү сыйфатын бәяләү өлкәсендә иң яхшы эксперт» гранты турында нигезләмә;

«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә ярдәм итү» гранты турында нигезләмә;

«Оста мөгаллим» гранты турында нигезләмә;

«Татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадаларында һәм татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадада җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән өчен татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм итү» гранты турында нигезләмә;

«Иң яхшы оста» гранты турында нигезләмә;

«Иң яхшы укытучы» гранты турында нигезләмә;

«Һөнәри белем бирү оешмасының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе» гранты турында нигезләмә;

«Иң яхшы мәктәп директоры» гранты турында нигезләмә;

«Безнең иң яхшы методист» гранты турында нигезләмә;

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмасының иң яхшы педагогы» гранты турында нигезләмә;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» гранты турында нигезләмә;

«Уңышлы мәктәп» гранты турында нигезләмә;

«Мәктәп укучыларының бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы җиңүчеләрен һәм призерларын әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм итү» гранты турында нигезләмә.

3. Грантларны түләү чыгымнары әлеге карар нигезендә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән максатларга «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы»ведомствосы буенча каралган акча хисабына башкарыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин